ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык беренче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
2. 2022 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабы.
3. 2022 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында доклад.
4. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2022 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап.
5. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 396-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» 382-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 393-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 385-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 388-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 391-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 389-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 392-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 386-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 394-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 387-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 384-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.

18. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның февраленә кадәрге эш чоры өчен хисабы.

19. Балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып бару чоры балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып баручы затларга картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукы бирүче эш стажына кертелә торган вазыйфалар һәм учреждениеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

20. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 289051-8 номерлы федераль закон проекты хакында (керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тикшерүне уздыру тәртибен камилләштерү һәм белешмәләрнең тулылыгы өлешендә).

21. «Дарулар әйләнеше турында» Федераль законның 53 һәм 67 статьяларына һәм «Эшчәнлекнең аерым төрләренә лицензия бирү турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 284099-8 номерлы федераль закон проекты турында (халыкара патентлаштырылмаган «Этанол» исемле дару препаратларын җитештерү күләмен һәм аларның әйләнешен исәпкә алуны камилләштерү өлешендә).

22. «Россия Федерациясе Торак кодексының $161^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 272604-8 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йорт советы рәисенең күпфатирлы йорттагы милекчеләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итү процедурасын гадиләштерү өлешендә).

23. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3 статьясына һәм «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның 11 һәм 16.5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 263340-8 номерлы федераль закон проекты турында (торак-төзелеш кооперативына әгъза итеп алынырга мөмкин булган гражданнар категориясе исемлеген киңәйтү өлешендә).

24. «Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{11}$ статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чиләбе өлкәсе Закон чыгару Собраниесе закон чыгару инициативасы хакында.

25. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 20.30 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 279585-8 номерлы федераль закон проекты турында (ягулык-энергетика

комплексы объектларының куркынычсызлыгын һәм террорчылыктан якланганлыгын тәэмин итү таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында).

26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 285558-8 номерлы федераль закон проекты турында (конфискацияләнгән җиңел сәнәгать товарларын түләүсез тапшыру мөмкинлеге хакында).

27. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү йомгаклары турында».

28. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1834-VI ДС